СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

28.06.2024 № 47/6

На № ________ от ____________

## КАРАР

**Тукай муниципаль районы территориясендә Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32.1 статьялары нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләре исемлеген раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Җир кодексы, 1998 елның 10 июлендәге 1736 номерлы Татарстан Республикасы Җир кодексы, «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32.1 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 25 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Тукай муниципаль районы уставы һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка норматив-хокукый актлар нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы территориясендә Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32.1 статьялары нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләре исемлеген расларга.
2. Әлеге карарны ТР муниципаль берәмлекләре порталы составында Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (https://tukay.tatarstan.ru/) урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары

Р.И. Закиров

Тукай муниципаль районы Советының 2024 елның ____ июнендәге ____ номерлы карарына кушымта

| Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Җир кишәрлегенең мәйданы | Җирләрнең категориясе |
|---|---|---|
| 16:39:040902:1288 | 1 087 731 кв. м | Торак пунктлар җирләре |